**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районы**

**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре, Совет мәйданы , 27**

**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Республика Татарстан**

**Муниципальное образование**

**город Арск**

**Арского муниципального района**
**Совет города Арск**
**422000, г.Арск, Советская площадь , 27**

**тел. 3-15-25, 3-16-25**

# КАРАР

**«09» декабрь 2020 ел** **№ 146**

**«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә Яңа ел бәйрәмнәре вакытында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында” 2020 елның 25 ноябрендәге 1062 номерлы карары нигезендә Яңа ел бәйрәме көннәрендә янгыннарны кисәтү һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге территориясендә кешеләр күпләп җыела торган урыннарда иминлекне тәэмин итү максатыннан Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Яңа ел бәйрәмнәре чорына, 2020 елның 20 декабреннән башлап 2021 елның 10 гыйнварына кадәр, «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә пиротехника чаралары куллану өчен түбәндәге мәйданчыкларны билгеләргә:

ТР, Арча муниципаль районы, Арча шәһәре, Тау асты урамы, 1а йорты адресы буенча урнашкан стадион;

- Арча-Казан, Арча-Сеҗе автомобиль юллары чатыннан Арча шәһәре, Күл урамына таба җәяүлеләр юлыннан уң якта 150 метр ераклыкта урнашкан мәйданчык;
- Төньяк-Көнбатыш юнәлештә Арча - Әтнә һәм Урта Бирәзә автомобиль юллары чатыннан 320 метр ераклыкта урнашкан мәйданчык;
- Арча-Төбәк-Чокырча автомобиль юлының уң ягында Иске Айван авылында автобус тукталышыннан 100 м ераклыкта урнашкан мәйданчык;
- Васильева Божа авылы Магистраль һәм Үзәк урамнар чатыннан 300 метр ераклыкта урнашкан мәйданчык;
- Күпербаш авылында Казансу елгасы аша күпердән 50 метр ераклыкта урнашкан мәйданчык.

2. Пиротехника чараларын  куллану өчен  махсус җиһазландырылган мәйданчыкларда урнаштырылган мәгълүмати стендларда, халык күп йөри торган  объектларда (кибетләр, сәүдә үзәкләре һ.б.) түбәндәгеләрне урнаштырырга:

-«Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим билгеләү турында» 2020 елның 25 декабрендәге 1062 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары;

- Арча шәһәре башкарма комитетының әлеге карары;

-пиротехника чаралары кулланганда янгын куркынычсызлыгы  буенча белешмә.

3. Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим кертү турында, «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә пиротехника чаралары җибәрү өчен мәйданчык билгеләү турында халыкка мәгълүмат җиткерүне оештырырга.

4. Яңа ел бәйрәмнәре чорына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

4.1. “Арча муниципаль районы идарәче компаниясе” ҖЧҖ һәм ТОС җитәкчеләренә Татарстан Республикасы территориясендә янгынга каршы махсус режим булдыру турындагы мәгълүматны җиткерергә. Пиротехник чаралар кулланганда куркынычсызлык таләпләрен үтәү турында халыкка мәгълүмат җиткерү эшен оештырырга, торак секторда куркынычсызлыкны тәэмин итәргә, подвал һәм чормаларны карап тотуга, аларга керү мөмкинлеген булдырмау максатыннан ишекләрне бикләүче җайланмаларның төзеклегенә аерым игътибар бирергә;

4.2. «Водоканал-сервис» ҖЧҖнә һәм балансларында янгынга каршы су белән тәэмин итү чыганаклары  булган предприятиеләргә аларны төзек хәлдә тотуга юнәлдерелгән чаралар күрергә, янгын сүндерү машиналарының су чыганакларына килә алуын тәэмин итәргә;

4.3 «Жилкомбытсервис» ҖЧҖенә «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге торак пунктларында янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын вакытында кардан һәм боздан чистартырга;

4.4 «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан авыл клублары мөдирләренә:

- Яңа ел бәйрәме чараларын уздыру вакытында кизү торуны оештырырга;

- янгын сүндерү чараларының төзеклеген тәэмин итәргә;

- ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә урамдагы чыршыларны бизәү өчен сертификацияләнгән электр гирляндалары гына  кулланырга;

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарлары Л.Р. Йосыповка һәм Р.Р. Баһаутдиновка йөкләргә.

Арча шәһәре Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймов